

Татар әдәбияты классигы, язучы һәм драматург Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев 1884 елнын 27 февралендә элекке Пенза губернасы Инсар оязе (хәзерге Мордва республикасынын Рузаевка районы) Татар Пешләсе авылында мулла гаиләсендә туган. Ромодан районы Ләбәжә-Алтар һәм Атюрьево районы Түбән Пешли - Нижний Пишляй мәдрәсәләрендә белем ала. Уналты яшендә атасы белән ачуланышып, Петербург - Казан тимер юл тозелешенә китеп урнаша. Аннары Истанбулдагы Дарелмогаллиминдә (педагогика институты) укуын дәвам итә. Икенче курстан сон Шәриф Каһирәгә китә, андагы университетнын ирекле тынлаучысы була. Матди кыенлыкларга күргәнгә, 1905 елда Россиягә әйләнеп кайта. Петербургта яшәүче абыйсы Гыймади Байгилдиев белән бергә могаллимлек кыла, сонышнан «Нур» газетасында хезмәт итә: мәкаләләр яза, тәржемә белән шогыльләнә, шигырьләр ижат итә. 1906 елда «Садә» («Аваз») исемле шигырьләр жыентыгы донья күрә.

1910 елда Оренбург шәһәренә китә. Анда «Вакыт» матбугатында хисапчы, корректор, әдәби хезмәткәр булып эшли. Бер үк вакытта әлеге газета һәм «Шура», «Кармак» журналлары битләрендә актив рәвештә үзенен әсәрләрен бастыра. Сәхнә әсәрләре күренә: «Акчарлаклар» (1914), «Хажи әфәнде ойләнә» (1915).

1925нче елдан - Казанда. Биредә ул соцреализм рухындагы әсәрләр яза: «Матур туганда», «Тан атканда» романнары, «Таулар», «Ут», «Козгыннар оясында», «Томан арты» пьесалары. Михаил Шолоховнын «Күтәрелгән чирәм»ен тәржемә итә.

1934 елда СССР Язучылар берлегенә алына. «Халык дош-маннары» Кәрим Тинчурин, Кави Нәжми, Гомәр Гали белән «элемтә тоткан очен» ВКП(б)дан чыгарыла. 1950 елда Островский урамындагы квартиры әдипнен Йорт-музее ителә.

Мордовиянен торле почмакларында Шәриф Камалга багышланган ачык дәресләр, класстан тыш чаралар үтә һәм үтәчәк. Республикабызда алдагы елларда да язучынын туган коннәре олылап үткәрелә иде.

Быел үтәчәк юбилей кичәсе турында да язачакбыз.